Регионыбызнын мәгариф учрежде-ниеләре очен җәйге каникуллар - яна уку елына топле әзерлек вакыты.
Мәсәлән, Торбеево районы Татар-Юнки, Краснополь һәм Жуков авыл мәктәпләрендә «Мәгариф» милли проекты кысаларында, тозелгәннән бирле модернизацияләнмәгән биналарга, капиталь ремонт йомгакланырга жыена. Объектлардагы эшләрнен барышы белән Мордовия Республикасы мәгариф министры Елена Солдатова танышты (рәсемдә). Мәктәпләрне реконструкцияләv подряд оешмалары тарафыннан сыйфатлы рәвештә, график, план кvләме һәм норматив срокларны vтәv буенча башкарыла, ә дәvләт бvлеп биргән һәр сум максималь нәтижәле тотыла.

Фасадлар янартылган, фундаментлар ныгытылган, тvбә монтажланган, тәрәзәләр, батарея радиаторлары һәм ишекләр урнаштырылган, идәннәр алыштырылган, баскыч маршлары ремонтланган, идәннәрне жылыту һәм гидроизоляция белән жыю башкарылган, идән япмасы жәелгән, сантехник система алмаштырылган, вентиляция монтажланган, биналарнын эчке бизәлеше тәмамланган стадиядә. Кабинетлар, спорт һәм актлар заллары, ашханә яна жиһазлар, компьютер һәм оргтехника, ашханә инвентары һәм савыт-саба белән жиһазландырыла. Мәктәп яны территориясе vзгәрә.

- Әлеге программаны мәктәпләрдә тормышка ашыру ремонт эшләре белән генә чикләнми. Ана инфраструктураны янарту, уку әсбаплары сатып алу, укытучыларнын квалификациясен кvтәрv, заманча инновацион технологияләрне vзләштерv керә. Бу vсеп килvче буынга vз сәләтләрен, мәнфәгатьләрен, задаткаларын тулысынча тормышка ашыру очен яхшы момкинлекләр бирәчәк, - дип билгеләп vтә Торбеево мәгариф учреждениеләре белән эшләv идарәсе башлыгы Елена Половникова.

[redacted]